**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

24 октябрь 2024 ел №102

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендәге 78/1 номерлы карары белән расланган Комыргуҗа авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 17 февралендәге 24-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Уставына таянып, Комыргуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендәге 78/1 номерлы карары белән расланган Комыргуҗа авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 2.2 пунктының 8 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2 3.8 пунктның «к» пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«к) Россия Федерациясенең Дәүләт чигенә федераль, төбәк яки муниципаль әһәмиятле автомобиль юлларына җитү урыннарында Россия Федерациясенең Дәүләт чиге аша үткәрү пунктлары урнаштырылырга мөмкин. Россия Федерациясенең Дәүләт чиге аша үткәрү пунктларын урнаштыру һәм эшләү тәртибе Россия Федерациясе Дәүләт чиге турында законнар нигезендә билгеләнә. Россия Федерациясе Хөкүмәте Россия Федерациясенең Дәүләт чиге аша автомобиль үткәрү пунктлары исемлеген билгели, аларга карата Россия Федерациясе Дәүләт чиген үтү максатларында датаны һәм вакытны резервлаштыру билгеләнә, шулай ук мондый автомобиль үткәрү пунктларына тоташа торган автомобиль юллары участоклары исемлеге, аларга карата "Россия Федерациясендәге автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2007 елның 8 ноябрендәге № 257-ФЗ Федераль законның 30.1 статьясында кертелә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Т.Гатауллин